#tatartabar

“Әгерҗе районы шәхесләре иҗаты - флеш-биремнәрдә” проектының продукты

Терентьева Люция Михаил кызы, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Сарсак-Омга лицеенның татар теле һәм әдәбият укытучысы

Максат – милли төбәк мирасына караган материалларны туплап, ФДББС шартларына туры килгән интерактив биремнәр төзү, аларны белем һәм тәрбия бирүдә файдалану.

Бурычлар:

- уку һәм укыту эшчәнлеген интерактив биремнәр төзү юнәлешендә оештыру;
- укучыларны дәрестән тыш эшчәнлек аша төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;
- тел берәмлекләрен үзләштерү аша балаларда регулятив, танып белү, коммуникатив күнекмәләр булдыру;
- профессиональ үсешне юнәлештә алып бару, татар теле укытучыларына методик ярдәм күрсәтү.

Сайтның эчтәлеге

- ✓ Төп бит
- ✓ Кабатлау (әлеге бүлектә фонетика, морфемика морфология, синтаксис, пунктуация, лексикологиягә караган тест биремнәре урнаштырылган);
- ✓ Проза һәм поэзия (татар әдәбиятыннан дәрестән тыш эшчәнлек өчен биремнәр)



- ✓ Әти-әниләр өчен виртуаль аралашу мәйданчыгы



Сайтның эчтәлеге



- ✓ Олимпиада
- ✓ Рус төркеме (рус төркемнәрендәге укучыларга биремнәр)
- ✓ Уеннар (ял вакыты өчен “Мантыйк кайда?” уеннары)
- ✓ Төрки телләр (төрки телдәге дәреслекләргә сылтама, табышмаклар)
- ✓ **Әгерҗе төбәгенең танылган шәхесләре**
- ✓ Район методик берләшмәсе бүлегендә аттестация сораулары һәм “Ел укытучысы” бәйгесенә әзерлек өчен киңәшләр урнаштырылган.

✓ **Әгерҗе төбәгенең танылган шәхесләре** - 14 язучы, шагыйрь, драматург, галим иҗатын туплаган флеш биремнәр тупламасы.



Сайттагы интерактив бирем төрләре:

- ✓ Төшеп калган сүзләрне, тыныш билгеләрен өстәп язу;
- ✓ Парларны туры китерү;
- ✓ Тәртип буенча тезү;
- ✓ Төркемнәргә-парларга аеры (сериация);
- ✓ Схемада тиешле терминны кую/язу;
- ✓ Викторина, филворд һәм башка иҗади биремнәр.

Якташыбыз Раиф Мәрданов



CORE

3нче сыйныф. Исем, сыйфат, фигыль темаларын кабатлау дәресе.

- https://coreapp.ai/app/player/lesson/5f3a78e0a3095246ac0a37b1

Әлеге видеоны карагач, без нәрсә белербез?



Җөмләләрне тулыландырып күчереп яз.

Дүрт ягы да … урман, Җиде чишмәле авыл. Нигезләнгәненә йөз ел, Җир җәннәте гүя ул.

Введите текст правильного ответа

Проверить

Җөмләләрне тулыландырып күчереп яз.

Җир бизәге, …сулы - Авыл исеме шуңа, Юл буеннан күренеп кала, Икәү безнең районда.

Введите текст правильного ответа

Проверить

Навигация

- Сайт ucoz платформасында төзелгән. “Татар теле укытучысы Терентьева Люция һәм укучылары сайты” белем бирү оешмасы проекты буларак теркәлгән, шунлыктан реклама банерлары юк.
- Биремнәрне дәрестә файдалану өчен махсус теркәлү таләп ителми.
- Биремнәрне эшләп бетергәч тикшерү мөмкинлеге бар.
- Яңа бүлеккә күчү өчен “меню”да теманы сайлап алырга кирәк.
- Кабатлау бүлегендә материал башлангыч, урта һәм югары сыйныф укучыларына аерым бүлекчәләргә куелган.

Татар халык мәкальләрен, табышмакларын өйрәнеп крафт ручкалар әзерләү

Якташ язучылар цитаталарын туплаган магнитлар

#әдәбимарафон

Тормыш аты алга бара,
Шыгырдатып арбасын.
Арбалар да туза инде,
Алып булмас янасын...

Әлфирә Низамова